ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.12.2016 Казан ш. № 7-22/т

Тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төрле машиналарның һәм аларга тагылма арбаларның техник торышына, шулай ук агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләренең үтәлешенә дәүләт күзәтчелеген үткәргәндә күрсәтелгән хезмәтләр өчен җыемнар күләмен билгеләү хакында

Россия Федерациясенең Салым кодексына, 2011 елның 1 июлендәге «Транспорт чараларын техник карау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 170-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1993 елның 13 декабрендәге «Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техникаларның техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында» 1291 номерлы, 2011 елның 5 декабрендәге «Транспорт чараларына техник карау үткәрү турында» 1008 номерлы, 2013 елның 13 ноябрендәге «Аларның техник торышына дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан теркәлгән үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техникаларны техник карау турында» 1013 номерлы карарларына, Федераль тарифлар хезмәтенең 2011 елның 18 октябрендәге «Техник карауны үткәргән өчен чик дәрәҗәдә түләү хисаплау методикасын раслау турында» 642-а номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 16 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төрле машиналарның һәм аларга тагылма арбаларның техник торышына, шулай ук агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләренең үтәлешенә дәүләт күзәтчелеген үткәргәндә күрсәтелгән хезмәтләр өчен җыемнар күләмен шушы карар кушымтасына туры китереп билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2009 елның 27 февралендәге «Тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төрле машиналарның һәм аларга тагылма арбаларның техник торышына, шулай ук агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләренең үтәлешенә дәүләт күзәтчелеген үткәргәндә махсуслаштырылган продукцияне сатканда һәм хезмәтләр күрсәткәндә гамәлгә ашырыла торган түләүләр күләмен билгеләү хакында» 7-3/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2009 елның 01 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2009 елның 27 февралендәге «Тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төрле машиналарның һәм аларга тагылма арбаларның техник торышына, шулай ук агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләренең үтәлешенә дәүләт күзәтчелеген үткәргәндә махсуслаштырылган продукцияне сатканда һәм хезмәтләр күрсәткәндә гамәлгә ашырыла торган түләүләр күләмен билгеләү хакында» 7-3/т номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 7-14/т карары.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
23.12.2016 № 7-22/э карарына
кушымта

Тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка төрле машиналарның һәм аларга тагылма арбаларның техник торышына, шулай ук агросәнәгать комплексында машиналарны һәм җайланмаларны эксплуатацияләү кагыйдәләренең үтәлешенә дәүләт күзәтчелеген үткәргәндә күрсәтелгән хезмәтләр өчен җыемнар күләме

| № п/п | Җыемнар күләменең аталышы | Җыем күләме, сум/бер. |
|---|---|---|
| 1. | Машиналарга һәм аларның тагылма арбаларын техник карау | 300,0 |
| 2. | Күзәтү машиналары һәм җайланмалары хуҗаларының сатылган яки төзекләндерелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавы турындагы ризасызлыкларын карап тикшерү комиссияләрендә катнашу | 237,0 |
| 3. | Күзәтү машиналарының һәм җайланмаларының калдык ресурсларын ачыклау | 300,0 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге